# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

**27.11.2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлыФедераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда 2500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пункты зираты территориясен төзекләндерү (үлән чаптыру, биек агачларны кисү һәм агач төпләрен кисү, чүп-чарны җыю һәм чыгару (килешү буенча эш өчен түләү);

2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пунктындагы чишмә территориясен төзекләндерү).

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман авылындагы мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырып халыкка чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы Башлыгы Р. Ә. Кәримов